| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2024 с. Сарманово № 240

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә яңа редакциядә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 1 абзацы, «Сарман муниципаль районы " муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районыСоветы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 20 ноябрендәге 198 номерлы Сарман муниципаль районы Советы карарына яңа редакциядә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 бүлекнең 3 пунктындагы 5 пунктчасына «һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә;
2) 1 нче кушымтаның 3.2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.2.5. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары җитәкчеләрен билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, үз урынбасарлары арасында вазыйфаларны бүлешә, муниципаль хезмәткәрләр һәм башкарма комитетның башка хезмәткәрләре вазыйфасына билгеләп куя, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата бүләкләү һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана (устав нигезендә башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләрен билгеләп кую муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы белән килештереп гамәлгә ашырыла.».

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район

Советы рәисе Ф.М. Хөснуллин